**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**

IV чакырылыш бишенче утырыш

07 апрель 2021 ел № 44 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу ш. т. поселогының
"Җирдән файдалану һәм төзелеш
Кагыйдәләренә үзгәрешләр
кертү турында" карар проекты хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 07.07.2003 ел, № 112-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 ел, № 18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 04.10.2018 ел, № 33 карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Таблицада 2.1 юлның 1 пунктның 1.1. пунктчасын «Ж1 - индивидуаль торак төзелеше зонасы» 25 статья “Шәһәр төзелеше регламенты билгеләнә торган территориаль зоналар»ны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре; җир кишәрлекләренең чик (минималь һәм (яки) максималь) зурлыклары һәм капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрлары:

| Рөхсәт ителгән куллану төре коды* | Рөхсәт ителгән куллану төре* | Җир кишәрлекләренең чик күләме һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү һәм реконструкцияләүнең чик параметрлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Җир кишәрлеге зурлыгы | Төзелешнең чик катлары саны һәм чик биеклеге | Төзелешнең максималь проценты | Җир кишәрлекләре чикләреннән чигерелгән минималь буш урын |
| **Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре** | | | | | |
| 2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен | минималь – 1000 кв. м; максималь – 2000 кв. м. | Төп төзелешнең катларының чик саны– 3 (мансардны да кертеп), ярдәмче корылмаларның - 1;<br>Төп төзелешнең чик биеклеге – 10 м; ярдәмче корылмаларның – 3,5 м (яссы түбәле), 4,5 м (авыш түбәле, “конек”ка кадәр биеклеге).<br>Ихаталарның максималь биеклеге – 2,0 м. | 20 % | Урам-юл челтәренә чыккан җир кишәрлеге яклары өчен - 3 м; җир кишәрлегенең башка яклары өчен - билгеләнми.<br>Барлыкка килгән төзелеш шартларында чигенүне киметү яки биналарны, корылмаларны һәм төзелешләрне кызыл линия буенча урнаштыру рөхсәт ителә. |

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу ш.т. поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектын карау буенча ачык тыңлауларны 2011 елның 13 маенда 17.00 сәгатьтә, түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш. т. п., Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының утырышлар залы.

3. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу ш. т. поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча килә торган тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия төзергә:

- Самонина С. П. - комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- Шәрипов Р. Ә. - комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;
- Галимҗанова Л. Ф. - комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы;
- Хисмәтуллин Р. В. - комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты;

- Вәлиев Р.К. - комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты;
- Идрисов Л.И. - комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы депутаты.

3. Комиссиягә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу ш.т. поселогының җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты белән танышкан вакытта әлеге проектның демонстратив материаллары экспозициясен оештырырга, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш. т. п., Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы адресы буенча кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен кабул итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы район
Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин